КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 5 май г.Казань № 670

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII1 бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында «Казан - Боровое Матюшино» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы адресы буенча урнашкан 796 кв.метр мәйданлы 16:24:260201:70 кадастр номерлы сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, мәгълүмат җирләре категорияләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона җирләре, иминлек җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясендәге җир кишәрлегеннән (алга таба - җир кишәрлеге) барлыкка килә торган 67 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба - алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә. Дәүләт милке чикләнмәгән алына торган җир кишәрлеге «Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыятенә арендага бирелгән (алга таба - алына торган җир кишәрлеге арендаторы).

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

2.1. 10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәсен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне.

2.2. Җир кишәрлеген алу турында килешү төзүне.

2.3. Алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында Казан - Боровое Матюшино автомобиль юлын реконструкцияләү» төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында» 2025 ел, 07 июль, 572 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектлары нигезендә алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләре үткәрүне;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләмен билгеләүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге арендаторына җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеген арендага алучы тарафыннан кул куелган килешү законнарда билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин